Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл Советы

КАРАР

26 октябрь 2023 ел №74

Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Миңлебай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 октяберендәге 22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 19 октябрендәге 02-08-02/1091 номерлы күрсәтмәсен карап

Миңлебай авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Миңлебай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 22 номерлы карарының 1 нче кушымтасына (Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл Советының 2022 елның 25 февралендәге 32 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 43 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 66 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяда:

а) җиденче абзацка «билгеләнә» сүзеннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 18 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

б) сигезенче абзацка «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 18 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

1.2. 11 статьяның 13 пунктының беренче абзацында «шәраб материаллары» сүзеннән соң «шикәрле эчемлекләр» сүзләрен өстәргә;

1.3. 24.1 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 25 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «программаны раслаган башкарма комитет карары нигезендә» сүзләрен «башкарма комитет билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче абзацта «үз көченә кергән көннән алып өч ай» сүзләрен «агымдагы финанс елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 26 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Миңлебай авылы, Ш.Бикчурин урамы, 50 йорт, Миңлебай станциясе, Шоссейная урамы, 20А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Миңлебай авыл
җирлеге башлыгы И.М. Рәхимов